Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге Советы

КАРАР

«19» октябрь 2021 ел № 30

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 февралендәге 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 февралендәге 36 номерлы белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү Тәртибенә (алга таба-тәртип), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. тәртипнең 5.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнар арасында сораштыру билгеләү турында карар Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайты файдаланылырга мөмкин. Гражданнарны сораштыру билгеләү турында карарда түбәндәгеләр билгеләнә:

сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

сораштырулар үткәргәндә тәкъдим ителә торган (тәкъдим ителгән) сораштыру (сораулар) формулировкасы;

сораштыру үткәрү методикасы;

сораштыру кәгазе формасы;

сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлек халкының минималь саны;

«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.».

1.2. Тәртипнең 17.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.1. Гражданнарны сораштыру әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чараларны финанслау түбәндәге чыганаклар хисабына гамәлгә ашырыла:

җирле бюджетның - җирле үзидарә органнары яисә муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә;

Татарстан Республикасы бюджетыннан - Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру үткәргәндә».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге
Советы рәисе Н.В. Авдеева